**ТАТАРСТАН Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**муниципаль беремлеге**
**Емелькино авылы**

**Республика ТАТАРСТАН**
**Аксубаевский**
**муниципальный район**
**муниципальное образование**
**село Емелькино**

# Совет Емелькинского сельского поселения

423056, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Емелькино, ул. Центральная д.16
Тел.(8-84344-4-76-22) ОГРН 1021605364980, ОКПО 94318599,ИНН/КПП 1603000796/160301001

КАРАР

№ 6 07 ноябрь 2022 ел

"Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең
Черёмушка авылында гражданнар җыенын
билгеләү, үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 9 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының "Емелькино авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка КФҮ бинасында түбәндәге адрес буенча : ТР, Аксубай муниципаль районы ,Емелькино авылы, Үзәк урамы, 16 йорт, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Черемушка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2023 елда Аксубай муниципаль районының Черемушка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, хәрби хезмәттә булган , өлешчә мобилизацияләү буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга алынган акчаларны юнәлдерергә ризамы :

1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пункт чикләрендә урамнарны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү);
-торак пункт чикләрендә вак таш түшәлгән юл полотносын урнаштыру -(сатып алу(китерү) -вак таш, ЩПС; эшләр өчен түләү-грунтны күтәрү, вак таш, ЩПС салу, су агызу торбалары сатып алу)
-торак пункт чикләрендә юлларны төзекләндерү (вак таш, ЩПС сатып алу)

2.Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, мотокосилка өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

3.Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен шартнамә буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

4. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру, халыкны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә ягулык белән тәэмин итү

- су белән тәэмин итү өчен тирән насос сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башлыгы Н.И.Михайлова

Р 06-641/13
СОВЕТ ЕМЕЛЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ